**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 600 (Алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Петропавловка авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Петропавловка авылында Крупская, Куйбышев, Мәскәү, Горький, Җиләкле, Елга урамнары буенча юлларны ремонтлау, грейдировкалау, кардан чистарту);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Петропавловка авылы территориясен коры үлән һәм чүп үләннәреннән чаптыру)

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Глазово авылы, Үрнәк-Күмәк ав., Мәктәп ур., 3а й., Глазово ав., Заречная ур., 13 й., Петропавловка ав., Горький ур., 19а й., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Глазово авыл җирлеге башлыгы Н.К.Карабаева